# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"

**1 статья.** "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре турында" 1990 елның 28 августында кабул ителгән Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1992, N1; N6) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре турында

Татарстан Республикасы
**З А К О Н Ы**

I. Даими комиссияләрне оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең төп принциплары, аларны төзү тәртибе

**1 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы халык депутатлары арасыннан беренче пленар сессиядә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләрен төзи һәм сайлый.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре чоры дәвамында яңа даими комиссияләр төзергә, элек төзелгәннәрен тар-

катырга һәм яңадан төзергә, шулай ук аларның составына үзгәрешләр кертергә мөмкин.

Даими комиссияләрнең вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре чоры узу белән бергә тәмамлана.

**2 статья.** Даими комиссияләр үз эшчәнлекләрендә Татарстан Республикасы һәм аның гражданнары ихтыяҗларыннан, хокукый дәүләт принципларыннан, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәүдән, Татарстан Республикасының суверенлыгын саклаудан һәм ныгытудан чыгып эш итәләр.

**3 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре закон проектларын әзерләүне алып бару, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагындагы мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен, шулай ук Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән башка карарларны тормышка ашыруга ярдәм итү һәм дәүләт органнарының, оешмаларының эшчәнлеген тикшереп тору өчен төзелә.

Үз карамагындагы мәсьәләләр буенча даими комиссия карарлар кабул итә һәм бәяләмәләр бирә.

Даими комиссиянең закон бозуларны төзәтүгә юнәлдерелгән карарларын үтәү мәҗбүри.

Даими комиссиянең законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарларын дәүләт һәм җәмәгать органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның караулары мәҗбүри. Кабул ителгән гамәлләр турында карар кабул ителгәннән соң бер ай эчендә яисә даими комиссия тарафыннан билгеләнгән башка вакытта даими комиссияләргә хәбәр ителергә тиеш.

**4 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алдында җаваплы һәм аңа хисап тоталар.

Даими комиссия үзенең эшен мәсьәләләрне коллектив, ирекле, эшлекле фикер алышу һәм хәл итү нигезендә,даими комиссия әгъзаларының хәбәрдарлыгы һәм киң инициативасы нигезендә кора.

Даими комиссияләр дәүләт, җәмәгать һәм фәнни оешмалар белән хезмәттәш булалар, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнәләр һәм

исәпкә алалар.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы даими комиссияләр эшчәнлеген җайга сала.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләренең эшчәнлеген җайга салуга бәйле рәвештә Дәүләт Советы Президиумы:

даими комиссияләрнең килешеп эшләүләрен, ә кирәк очракта бергәләп эшләүләрен оештыру буенча кирәкле гамәлләр кабул итә;

закон проектларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумының башка актларын алдан карау яисә өстәмә карау өчен Дәүләт Советының тиешле даими комиссияләренә тапшыра;

баш даими комиссияләрне билгели, шулай ук закон проектлары буенча бәяләмәләрнең һәм тәкъдимнәрнең әзерлеге хакында даими комиссияләрнең мәгълүматларын тыңлый.

Бер үк мәсьәлә буенча комиссияләрнең фикерләре туры килмәгән очракта, алар каршылыкларны бетерү өчен чаралар кабул итәләр. Әгәр даими комиссияләр уртак фикергә килмәсәләр, алар үз фикерләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына җиткерәләр. Даими комиссия әлеге мәсьәлә буенча үзенең фикерен Дәүләт Советына мөстәкыйль рәвештә җиткерергә дә хаклы.

**5 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының эшчәнлеген тәэмин итүче юнәлешләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә даими комиссияләр төзи. Даими комиссияләрнең санын һәм исемнәрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгели.

**6 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре, кагыйдә буларак, ачык тавыш бирү юлы белән комиссиянең рәисе һәм әгъзалары составында сайлана.

Даими комиссияләрнең санлы һәм шәхси составы Дәүләт Советының беренче пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатларының теләкләрен исәпкә алып билгеләнә, әмма даими комиссиянең санлы составы кимендә җиде һәм күп дигәндә егерме Татарстан Республикасы халык депутатыннан торырга тиеш.

Әгәр башкасы хәл ителмәгән булса, даими комиссияләрне сайлаганда тавыш бирү тулаем даими комиссия составы буенча үт-

кэрелэ.

Даими комиссиялэрнең рэислэре, кагыйдэ буларак, Татарстан Республикасы Дэүлэт Советының пленар сессиясендэ альтернатив нигездэ сайланалар. Даими комиссия рэисе урынына чыгарга телэүче кандидатуралар аның утырышында каралырга тиешлэр.

Халык депутатларыннан торган даими комиссия рэис урынбасарын, сэркэтибен, кече комиссиялэрнең рэислэрен сайлап куярга хаклы. Рэис урынбасары һэм сэркэтип кандидатураларын даими комиссия рэисе фикер алышуларга тэкъдим итэ.

Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы Дэүлэт Советының бары тик бер генэ даими комиссиясе эгъзасы була ала.

**7 статья.** Татарстан Республикасы Дэүлэт Советы Рэисе, аның урынбасарлары, Дэүлэт Советы Секретаре, Президиум эгъзалары, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Дэүлэт Советының Парламент контроле комитеты рэисе Татарстан Республикасы Дэүлэт Советы даими комиссиялэренең эгъзалары булып сайлана алмыйлар.

## II. Даими комиссиялэр карамагындагы мэсьэлэлэр

**8 статья.** Татарстан Республикасы Дэүлэт Советының даими комиссиялэре карамагындагы мэсьэлэлэр, аларның хокуклары һэм бурычлары, оештыру һэм эшчэнлек тэртибе Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Дэүлэт Советы Регламенты, элеге Закон һэм Татарстан Республикасының башка закон актлары тарафыннан билгелэнэ.

**9 статья.** Татарстан Республикасы Дэүлэт Советы даими комиссиялэренэ үз вэкалэтлэре кысаларында түбэндэгелэр йөклэнэ:

закон проектларына һэм башка закон актларына төзэтмэлэр, кисэтүлэр һэм тэкъдимнэр буенча бэялэмэлэр эзерлэү;

Татарстан Республикасы Дэүлэт Советы кушуы яисэ үз инициативасы буенча закон проектларын яки башка закон актларын эзерлэү;

Татарстан Республикасы Дэүлэт Советы яисэ аның Президиумы кушуы буенча Россия Федерациясе закон актларының проектларына

кисәтүләр, тәкъдимнәр һәм төзәтмәләр әзерләү яисә мондый актларның проектларын әзерләү;

Татарстан Республикасы законнарын чыгаруны системалаштыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгән һәм сайлау, билгеләү яисә раслау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителгән кандидатуралар буенча алдан фикер алышу һәм каралган кандидатуралар буенча бәяләмәләр бирү;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты нигезендә яисә Дәүләт Советы кушуы буенча башка даими комиссияләр белән берлектә Татарстан Республикасының икътисадый һәм җәмгыяви үсеше буенча мөһим дәүләт программалары һәм Татарстан Республикасының дәүләт бюджеты буенча, шулай ук программаларның һәм бюджетның үтәлеше хакында хисаплар буенча бәяләмәләр әзерләү һәм әлеге бәяләмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итү;

Татарстан Республикасының икътисадый һәм җәмгыяви үсеше буенча дәүләт программаларының, дәүләт бюджетының билгеләнгән тәртиптә кертелгән проектларын һәм программаларның, бюджетның үтәлеше хакындагы хисапларны мөстәкыйль карау, шулай ук алар буенча бәяләмәләр әзерләү;

закон чыгару инициативасы хокукына ия булган субъектлардан даими комиссияләргә кергән законнарны үзгәртүгә, Татарстан Республикасының икътисадый һәм җәмгыяви үсеше буенча дәүләт программаларының һәм дәүләт бюджетының күрсәткечләрен үзгәртүгә кагылышлы тәкъдимнәрне карау;

тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарның үтәлеше турындагы һәм дәүләт, хуҗалык һәм җәмгыяви-мәдәни төзелеш турындагы мәсьәләләрне Дәүләт Советы яисә аның органнары утырышларында карау өчен әзерләү юлы белән дә;

тиешле министрлыкларның, дәүләт комитетларының һәм республика оешмаларының башка ведомстволарының, җирле дәүләт органнарының, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның хисапларын, мәгълүматларын һәм нотыкларын тыңлау;

законнарны бозу турында материалларны прокуратура органнарына яисә башка оешмаларга җибәрү.

**10 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының берничә даими комиссиясе карамагындагы мәсьәләләрне үз инициативалары, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы яисә аның Президиумы кушуы буенча даими комиссияләр бергәләп әзерләргә һәм карарга мөмкин.

Карала торган мәсьәләр буенча даими комиссия башка даими комиссияләрнең фикерләрен соратып алырга мөмкин.

**11 статья.** Әгәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссиясе үз карамагына тапшырылган мәсьәләне башка даими комиссиягә дә кагыла дип санаса яисә бүтән даими комиссиядә каралучы мәсьәлә буенча үз фикерен белдерүне кирәк дип тапса, ул бу хакта Татарстан Республикасы Дәүләт Советына яки аның Президиумына тәкъдим кертергә, шулай ук карала торган мәсьәлә буенча аларга үз фикерен җиткерергә хаклы.

Бүтән даими комиссияләрдә мәсьәләләр каралганда, шушы даими комиссиянең үтенече буенча даими комиссия мәсьәләләрне әзерләүдә катнаша ала.

## III. Даими комиссияләрнең хокуклары һәм бурычлары

**12 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре үз эшчәнлекләрендә бертигез хокуклардан файдаланалар һәм бертигез бурычларга ия.

**13 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия.

**14 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре үз карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы утырышларында нотыклар һәм өстәмә нотыклар белән чыга алалар.

Даими комиссияләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм аның Президиумына керткән мәсьәләләре яисә бүтән даими комиссияләргә алдан карау яки өстәмә карау өчен бирелгән мәсьәләләре буенча үзләренең нотыкчыларын яисә өстәмә нотыкчыларын

билгелиләр.

Даими комиссияләр тарафыннан бергәләп әзерләнгән мәсьәләләр буенча алар уртак нотыклар һәм уртак өстәмә нотыклар белән чыга яисә үз кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен аерым бирә алалар.

Даими комиссия карамагына кертелүче мәсьәләләрне әзерләү һәм карау тәртибе даими комиссия тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

**15 статья.** Законнар һәм башка актлар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан, кагыйдә буларак, аларның проектлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле даими комиссияләрендә алдан каралганнан соң кабул ителә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре Татарстан Республикасы законнары проектларын яисә республикадагы дәүләт тормышының башка мөһим мәсьәләләрен җәмәгатьчелек хөкеменә чыгару турындагы яисә парламент тыңлаулары уздыру турындагы тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына йә аның Президиумына кертергә хаклы.

Җәмәгатьчелек хөкеменә чыгарылган закон проектлары һәм башка мәсьәләләр буенча гражданнардан, учреждениеләрдән һәм оешмалардан алынган тәкъдимнәр һәм парламент тыңлаулары тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгеләгән тәртип тиешле даими комиссияләр тарафыннан мөстәкыйль яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тәкъдиме буенча каралалар һәм гомумиләштереләләр.

**16 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре үз карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кушуы буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте әгъзаларын һәм җирле хакимият башлыкларын, халык депутатларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы буйсынуындагы җирле Советлары рәисләрен, дәүләт органнары җитәкчеләрен тыңларга хаклы.

Күрсәтелгән затлар даими комиссия тәкъдиме буенча даими комиссия утырышына килергә һәм даими комиссиядә каралучы мәсьәлә буенча язмача яисә телдән аңлатма бирергә тиешләр. Даими комиссияләр каралучы мәсьәләләр турында тиешле органнарга алдан хәбәр итәләр һәм фикер алышуга куелучы мәсьәләләр буенча

материаллар бирүнең вакытларын һәм рәвешен билгелиләр.

**17 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына буйсынган дәүләт органнарыннан һәм аларның урындагы затларыннан үз эшчәнлекләренә бәйле документларны, язма бәяләмәләрне, хисап мәгълүматларын һәм башка материалларны бирүне таләп итәргә хаклы.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына буйсынган Дәүләт органнары һәм аларның урындагы затлары даими комиссияләрнең таләпләрен үтәргә һәм аларга тиешле материалларны һәм документларны бирергә тиеш.

**18 статья.** Даими комиссияләрнең карарларын үтәүдән баш тарткан, шулай ук утырышка килми калган, таләп ителгән документларны, материалларны яисә башка мәгълүматларны даими комиссиягә бирүдән баш тарткан яисә ялган белешмәләр йә мәгълүматлар биргән затлар законнар нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

**19 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына тәкъдимнәр белән керергә хаклы.

Даими комиссияләр Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына, Премьер-министрга, министрларга, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан оештырылучы, сайланучы һәм раслаучы башка органнарның җитәкчеләренә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләренә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагындагы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итә алалар.

**20 статья.** Даими комиссия аерым мәсьәләләрне әзерләү өчен Татарстан Республикасы халык депутатлары арасыннан, шулай ук министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары, башка дәүләт органнары һәм җәмәгать берләшмәләре, фәнни учреждениеләр вәкилләреннән, Дәүләт Советы Аппараты вәкилләреннән һәм башка белгечләрдән эшче төркемнәр төзи ала.

Даими комиссия үз эшенә экспертларны җәлеп итәргә, закон проектларына бәйсез экспертиза билгеләргә хаклы.

Экспертиза өчен түләү тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы раслаучы нигезләмә тарафыннан билге-

ләнә.

**21 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләренең әгъзалары даими комиссияләрнең эшчәнлегендә катнашырга, даими комиссияләрнең йөкләмәләрен үтәргә тиешләр.

Даими комиссия әгъзасы даими комиссия карый торган барлык мәсьәләләр буенча хәлиткеч тавышка ия була.

Даими комиссия әгъзасы түбәндәгеләргә хаклы:

даими комиссиядә карау өчен мәсьәләләр тәкъдим итәргә һәм аларны әзерләүдә, алар буенча фикер алышуда катнашырга;

дәүләт органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшен тикшерүне үткәрүнең зарурлыгы турындагы, даими комиссия утырышында аларның җитәкчеләренең хисапларын яисә мәгълүматларын тыңлау хакындагы тәкъдимнәрне кертергә.

Даими комиссия тарафыннан хуплау тапмаган тәкъдимнәрен даими комиссия әгъзасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советына яисә аның органнарына язмача яки телдән кертә ала.

Даими комиссия әгъзасына даими комиссиядә каралучы барлык мәсьәләләрне хәл иткәндә катнашу өчен шартлар тудырыла, моның өчен аңа үз вакытында кирәкле документлар һәм материаллар, шулай ук даими комиссия алган барлык материаллар турында мәгълүмат җибәрелә.

Даими комиссия Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алдында даими комиссия эшеннән даими рәвештә читләшкән Татарстан Республикасы халык депутатының җаваплылыгы турындагы мәсьәләне, хәтта даими комиссия составыннан чыгаруга кадәр, шулай ук үз вазыйфаларын тиешенчә үтәми торган даими комиссия рәисен яңадан сайлау мәсьәләсен куярга хаклы.

**22 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләренең әгъзалары даими комиссия кушуы һәм үз инициативасы буенча даими комиссия карамагындагы мәсьәләләрне өйрәнәләр, дәүләт һәм җәмәгать органнарының, оешмаларының, шулай ук гражданнарның тәкъдимнәрен гомумиләштерәләр, даими комиссиягә үзләренең нәтиҗәләрен һәм тәкъдимнәрен җиткерәләр.

**23 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими рәвештә эшләмәүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими

комиссияләренең әгъзалары даими комиссия утырышлары чорына, шулай ук даими комиссияләрнең йөкләмәләрен үтәү өчен, аларга депутат эшчәнлегенә бәйле чыгымнарын Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары хисабыннан түләп, җитештерү һәм хезмәт вазыйфаларыннан азат ителәләр.

## IV. Даими комиссияләрнең эшләү тәртибе

**24 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре үз утырышларында расланган планнар нигезендә эшлиләр. Даими комиссияләрнең эш планнары барлык даими комиссияләр эшчәнлеген килештерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына тәкъдим ителә.

**25 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләренең утырышлары кирәк очракта, әмма кварталга кимендә бер тапкыр чакырыла. Даими комиссия утырышлары Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә үткәрелә.

**26 статья.** Әгәр утырышта даими комиссия составының кимендә өчтән икесе катнашса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссиясенең утырышы хокукый көчкә ия була.

Даими комиссия әгъзасы утырышка килә алмаганда, бу хакта даими комиссия рәисенә яисә аны алыштыручы затка хәбәр итә.

**27 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссиясенең карары даими комиссия утырышында катнашучы әгъзалар санының күпчелеге тавышы белән кабул ителә.

Берничә даими комиссия утырышларын бергә үткәргәндә, карарлар һәр даими комиссиянең утырышында катнашучы әгъзалар санының күпчелеге тавышы белән кабул ителә.

**28 статья.** Даими комиссия утырышында киңәш итү хокукы белән аның составына кермәгән Татарстан Республикасы халык депутатлары да катнаша ала.

**29 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләре утырышларына дәүләт һәм җәмәгать органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар вәкилләре, белгечләр һәм галимнәр чакырылырга мөмкин. Даими комиссия утырышларына чакырылган белгечләр, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре рәислек итүче тәкъдиме яисә депутат үтенече буенча белешмәләр һәм аңлатмалар бирәләр.

Кирәк очракта, даими комиссия ябык утырыш үткәрү турында карар кабул итәргә мөмкин. Ябык утырыш үткәрү турындагы карар даими комиссиядә катнашучы әгъзалар санының өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.

**30 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссиясе рәисе яисә аның урынбасары:

даими комиссия утырышларын чакыра һәм утырышлар өчен кирәкле материалларга әзерлекне оештыра;

даими комиссия составының кимендә биштән бере, әмма даими комиссиянең кимендә өч әгъзасының таләбе буенча, җиде көннән дә соңга калмыйча, даими комиссия рәисе утырыш чакырырга тиеш, утырышны чакыру инициаторлары даими комиссияне чакыруга ләмә таләп белән бергә даими комиссиядә тикшерелүгә чыгарыла торган мәсьәләләрне дә тәкъдим итәргә тиеш;

халык депутатларының даими комиссия эшчәнлегенә бәйле материаллар һәм документлар белән вакытында тәэмин ителешен тикшереп тора;

әзерлек комиссияләрендә һәм эшче төркемнәрдә эшләү, шулай ук даими комиссиянең башка йөкләмәләрен үтәү өчен даими комиссия әгъзаларын чакыра;

даими комиссия утырышларында катнашу өчен дәүләт һәм җәмәгать органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар вәкилләрен, белгечләрне һәм галимнәрне чакыра;

даими комиссия утырышларына рәислек итә;

даими комиссиянең башка дәүләт һәм җәмәгать органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга карата мөнәсәбәтен белдерә;

даими комиссия карарларының үтәлешен оештыра һәм тикшереп тора;

даими комиссия әгъзаларына даими комиссия карарларының

үтәлеше һәм аның тәкъдимнәрен карау турында, шулай ук даими комиссиягә килгән барлык документлар турында мәгълүмат бирә һәм депутатның үтенече буенча әлеге документларның нөсхәләре белән тәэмин итә;

даими комиссия карарлары тарафыннан билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Даими комиссияләрнең уртак утырышларын үзара килешү буенча әлеге даими комиссияләрнең рәисләре алып бара.

**31 статья.** Даими комиссиянең сәркатибе килештерү эшчәнлеген башкара һәм йөкләмәләрне үтәүнең, комиссия утырышларының беркетмәләрен һәм стенограммаларын алып баруның барышын, аларның эчтәлекләренең даими комиссия әгъзаларына җиткерелүен, шулай ук башка документларны язуның барышын тикшереп тора.

**32 статья.** Ярдәмче комиссия рәисе әлеге Законның 30 статьясы нигезендә ярдәмче комиссияне алып бару мәсьәләләре буенча вәкаләтләргә ия була, аның карарларына һәм беркетмәләренә имза сала, шулай ук ярдәмче комиссия йөкләмәләренең үтәлешен тикшереп тора.

**33 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләренең карарлары һәм бәяләмәләре даими комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

Даими комиссияләр тарафыннан уртак кабул ителгән карарлар һәм алар биргә әзерләгән бәяләмәләр тиешле даими комиссияләрнең рәисләре тарафыннан имзалана.

Даими комиссия утырышларының беркетмәләренә комиссиянең сәркатибе имза сала. Даими комиссияләрнең уртак утырышлары беркетмәләрен тиешле даими комиссияләрнең сәркатипләре имзалый.

**34 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләре җәмәгатьчелеккә үз эшчәнлекләре турында хәбәр итәләр. Даими комиссияләрнең, аларның ярдәмче комиссияләренең һәм эшче төркемнәренең утырышларына матбугат органнары, телевидение, радио һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

Даими комиссияләрнең эше турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Дәүләт Советының матбугат органнарында һәм башка массакүләм матбугат чараларында яктыртыла.

**35 статья.** Даими комиссияләр эшчәнлегенең хокукый, оештыру, документаль, мәгълүмати һәм матди-техник тәэминатын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Президенты - М.Шәймиев

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ СЕКТОР
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан шәһәре,

1996 елның 7 феврале.
№ 417